**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КӘКРЕ КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**КАРАРЫ**

№ 3 7 ноябрь 2022 ел.

**"Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең Яңа Александровка авылында гражданнар җыенын билгеләү: үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Кәкре Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 18 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка түбәндәге адрес буенча Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең Яңа Александровка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә: ТР, Аксубай муниципаль районы, Яңа Александровка авылы, Энгельс урамы, 10 нчы йорт янында .
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2023 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре күл авыл җирлегенең Яңа Александровка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертү : I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Федерациясе Хәрби хезмәтенең сроклы хезмәтендәге хәрбиләрдән, Украинада спецоперациядә катнашырга мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш; алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

**Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- Яңа Александровка авылы урам яктыртуын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

**Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;**

- Вак таш түшәлгән юллар төзү (таш алу, ташу, җәю, вак ташны тигезләү, ком һәм грунттан нигез салу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) Яңа Александровка авылында Энгельс урамы; Карл Маркс урамы,

- Кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту (урамнарны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү) Яңа Александровка авылы.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны авыл җирлеге мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
4. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Аксубай муниципаль районы
Кәкре Күл авыл җирлеге башлыгы С.С.Елисеев